9·10
1997

НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ

Сабыйга

№ 9-10 (39-40) — 1997 ел.
(сентябрь-октябрь)

Балаларның
әдәби-нәфис журналы

ОЕШТЫРУЧЫЛАР:
«Сабыйга» журналы
редакциясе хезмәт коллективы,
Казан шәһәр хакимияте,
«Мирас» журналы редакциясе,
Татарстан белем министрлыгы

Баш мөхәррир
МИҢНӘХМӘТ СӘХАПОВ

Редакция советы:
Алла Айсина
Ришат Әбүбәкеров
Фаил Әхмәдиев
Шәүкәт Галиев
Мөнәвир Галимуллин
Фердинанд Галәмиев
Җәүдәт Дәрзаманов
Айрат Зарипов
Фирдәвес Зарифуллин
Фәрит Ишмаков
Аркадий Мельников
Роберт Миңнуллин
Флүн Мусин
Алия Сальникова
Лилия Сәхапова
Фарис Харисов
Вахит Хаков
Мөсәгыйт Хәбибуллин
Зөфәр Хәкимов
Әнәс Хәсәнов
Рәүф Хөснетдинов
Фәнис Яруллин

Т ы ш л ы к т а
Светлана Ибраһимова рәсемнәре.

«Сабыйга» балалар журналының индексы — **73954.** Аңа Татарстан Республикасының, Русия Федерациясе составында булган республикаларның, край һәм өлкәләрнең, БДБ составына кергән дәүләтләрнең һәм чит илләрнең элемтә бүлекләрендә чикләнмәгән күләмдә язылырга мөмкин. Журнал татар һәм урыс телләрендә нәшер ителә. Редакциянең адресы: 420066, Казан шәһәре, Чистай урамы, 5 йорт. Бәйләнешкә керү өчен телефон: ***(8432)* 49-35-54**. Журналга язылу һәм аны тарату мәсьәләләре буенча 38-59-54 номерлы телефон аша мөрәҗәгать итәргә, ә басманың сыйфатына кагылышлы дәгъваларны исә 49-36-62 номерлы телефон ярдәмендә белдерергә мөмкин. Иганәчеләр өчен журналның исәп-хисап саны: **р/с № 049345602,** Россия Саклык банкының Татарстан Банкы 6672/0253. Корр. счеты № 600164503. Журнал идеясенең һәм исеменең авторы М. Җ. Сәхапов.
«Сабыйга» журналы Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 314 сан белән теркәлде. 1994 елның 1 июленнән бирле нәшер ителә.

Производствога бирелде 5.05.97 ел. Басарга кул куелды 25.09.97 ел. Форматы 84 × 108 $^{1}/_{16}$. Күләме 2,0 (2,1) басма табак. 3,36 нәшер-хисап табак. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 7000 данә. Заказ Н-200. Ваклап сатуда ирекле бәя.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе. 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт.

© «Сабыйга», 1997 ел.



Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМОВ

СЕНТЯБРЬ

КЫР КАЗЛАРЫ ОЧАЛАР — КЫШНЫ СӨЙРӘП КИЛӘЛӘР.
ӘГӘР ӘБИЛӘР ЧУАГЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ КӨНЕ
АЯЗ БУЛСА, КӨЗ ДӘ ҖЫЛЫ БУЛЫР.
СУГАН БЕЛӘН МУНЧА БАРЫСЫНА ДА ХУҖА.
СЕНТЯБРЬДӘН АЛМА ИСЕ,
Ә ОКТЯБРЬДӘН КӘБЕСТӘ ИСЕ КИЛӘ.

ОКТЯБРЬ

ОКТЯБРЬ — КЫШНЫҢ ТУГАН ЭНЕСЕ.
КӨЗГЕ КАР ОЗАК ЯТМЫЙ, ТӨШҮГӘ ЭРЕП БЕТӘ.
ОКТЯБРЬДӘ АЙ УРАККА ОХШАСА, ҖӘЙ КОРЫ КИЛЕР.
КАРГА ОЧЫП КИТСӘ, КАР ТӨШӘР.

СЕНТЯБРЬ

ГУСИ ЛЕТЯТ — ЗИМУШКУ НА ХВОСТЕ ТАЩАТ.
ЕСЛИ ПЕРВЫЙ ДЕНЬ БАБЬЕГО ЛЕТА ЯСЕН,
ТО И ОСЕНЬ БУДЕТ ТЕПЛАЯ.
ЛУК ДА БАНЯ ВСЕМ ПРАВЯТ.
СЕНТЯБРЬ ПАХНЕТ ЯБЛОКАМИ, А ОКТЯБРЬ КАПУСТОЙ.

ОКТЯБРЬ

ОКТЯБРЬ — ЗИМЕ РОДНОЙ БРАТ.
ОСЕННИЙ СНЕЖОК — НЕ ЛЕЖОК: ВЫПАЛ ДА ТАЕТ.
В ОКТЯБРЕ ЛУНА К КРУГУ — ЛЕТО СУХОЕ БУДЕТ.
КОГДА ГРАЧ УЛЕТАЕТ — СНЕГ ВЫПАДАЕТ.

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ.

Сабыйга

№ 9-10 (39-40) — 1997 г.
(сентябрь-октябрь)

Детский литературно-художественный журнал

УЧРЕДИТЕЛИ:
Трудовой коллектив редакции журнала «Сабыйга», администрация г. Казани, редакция журнала «Мирас», Министерство образования Татарстана

Главный редактор
МИНАХМЕД САХАПОВ

Совет редакции:
Ришат Абубакиров
Алла Айсина
Фаил Ахмадеев
Шаукат Галиев
Мунавир Галимуллин
Фердинанд Галямиев
Джавдат Дарзаманов
Айрат Зарипов
Фирдаус Зарифуллин
Фарид Ишмаков
Аркадий Мельников
Роберт Миннуллин
Флюн Мусин
Алия Сальникова
Лилия Сахапова
Фарис Харисов
Мусагид Хабибуллин
Вахит Хаков
Зуфар Хакимов
Анас Хасанов
Рауф Хуснутдинов
Фанис Яруллин

На обложке рисунки Светланы Ибрагимовой.

Индекс детского журнала «Сабыйга» — **73954**. Подписка на журнал производится без каких-либо ограничений во всех отделениях связи Республики Татарстан, в областях, краях, республиках Российской Федерации, в государствах Ближнего и Дальнего Зарубежья. Журнал выходит на татарском и русском языках. Адрес редакции: 420066, г. Казань, ул. Чистопольская, 5. Тел.: ***(8432)* 49-35-54**; а/я № 227. По вопросам доставки и подписке обращаться по телефону: 38-59-54, качества печати 49-36-62. Для спонсоров журнала: **р/с № 049345602** в Банке Татарстан Сбербанка России. Корр. счет № 600164503 в РКЦ НБ РТ, БИК 049205603. ИНН № 1654002150. Код ОКОНХ — 87100, код ОКПО — 12986213. Журнал «Сабыйга» зарегистрирован в Мининформпечати РТ. Свидетельство № 314. Выходит с 1 июля 1994 года.

Автор идеи и названия журнала М. Ж. Сахапов.

Сдано в производство 5.05.97 г. Подписано в печать 25.09.97 г. Формат 84 × $108^1/_{16}$. Объем 2,0 (2,1). Учетн.-изд. л. 3,36. Печатается офсетным способом. Тираж 7000 экз. Заказ Н-200. Цена договорная.

Типография газетно-журнального издательства. 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

© «Сабыйга», 1997 г.

Җәнлекләр дөньясы
Мир животных

БҮРЕ

Бүреләргә мөнәсәбәт соңгы дистә еллар арасында кисәк кенә үзгәрде. Ул күп санда йорт хайваннарын юк итә, котыру авыруын тарата һәм һичсүзсез, тулысынча юк ителергә тиеш, дип яздылар. Аннан соң, кыргый тояклыларның санын адәм баласы контрольдә тота алмаган очракта бүренең урман санитары булып, көтүнең гомуми халәтен яхшыртуын ачыкладылар.

Бүре парлары гадәттә бөтен гомерләре буена кушылалар. Еш кына февраль уртасында була торган кушылудан соң, ата бүре белән ана бүре урман эчендәге аулак чокырда оя өне ясыйлар. Кагыйдә буларак, өн судан ерак булмаган җирдә корыла. Апрель аенда ана бүре өчтән алып уникегә кадәр сукыр балалар таба. Алар унберенче көнне күрә башлыйлар. Яшь бүреләр үсә барган саен аларның азыкка булган ихтыяҗы да арта бара һәм ата бүре белән ана бүре өннәреннән еш китә башлыйлар.

Июль-август айларында үсеп җиткән бүре балалары азык эзләргә үзләренең әти-әниләре белән бергә йөри башлыйлар.

Урысчадан ***ЛИЛИЯ СӘХАПОВА*** *тәрҗемәсе.*

Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМОВ

ВОЛК

Отношение к волкам резко менялось даже в течение последних десятилетий. Писали, что он уничтожает большое количество домашних животных, разносит бешенство и, безусловно, подлежит полному уничтожению. Затем, выяснили, что там, где человек не может контролировать численность диких копытных, волк является санитаром леса, улучшая общее состояние стада.

Волчьи пары соединяются обычно на всю жизнь. После спаривания, которое происходит чаще в середине февраля, волк с волчицей подыскивают в глухом, уединенном лесном овраге, на сухой гриве среди болот место, где устраивают гнездовую нору. Как правило, нора устраивается недалеко от воды. В апреле волчица приносит от 3 до 12 слепых щенят, прозревающих на 11-й день. По мере роста молодых увеличивается потребность в пище, и родители все чаще и чаще покидают логово.

В июле-августе подросшие волчата начинают выходить на добычу вместе с родителями, а с первых чисел августа до начала октября — пока выводок еще держится около норы — на утренних и вечерних зорях можно услышать вой волков. Специалисты-охотники в это время прекрасно подвывают им и таким образом определяют места их обитания.

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ

САЛАВАТ КҮПЕРЕ НӘРСӘ УЛ?

Салават күпере — табигатьнең иң гүзәл күренешләреннән берсе һәм кешеләр күптән инде аның табигате хакында уйлаганнар. Хәтта борынгы грек фәлсәфәчесе Аристотель дә салават күперенең сәбәбен аңлатырга омтылып караган.

Кояш нурында яки яктылыкның гадәти нурында чынбарлыкта булган барлык төсләрне дә табып була. Син, мөгаен, көзгенең кыегайган читенә яки сабын куыгының өстенә яктылык нуры төшкән чакта нәрсә буласын чамалыйсыңдыр. Ак нур төрле төсләргә таркала. Без кызыл, кызгылт сары, сары, яшел, зәңгәр һәм шәмәхә төсләр күрәбез.

Яктылык нурын төрле төсләргә тарката алучы җисем «призма» дип атала. Пәйда булучы төсләр «спектр» дип аталган төсле линияләр тезмәсеннән тар кисәк хасил итәләр.

Салават күпере — ул бөгелгән зур спектр яки яңгыр тамчылары аша үткәндә яктылык нуры таркалу нәтиҗәсендә барлыкка килгән төсле линияләр кисәге. Бу очракта яңгыр тамчылары призма вазыйфасын башкаралар.

Салават күпере бары тик ташу вакытында, берүк вакытта яңгыр яуганда һәм кояш яктырганда гына күренә. Моның өчен кояш (ул артта булырга тиеш) һәм яңгыр (ул синең алда булырга тиеш) арасында торырга кирәк. Югыйсә, салават күперен күреп булмас! Кояш, сезнең күзләр һәм салават күпере үзәге бер линиядә булырга тиешләр!

Әгәр кояш күктә бик югары икән, андый туры линияне үткәрү мөмкин түгел. Менә ни өчен салават күперен бары бик иртән яки кичкә таба гына күзәтергә мөмкин. Иртәнге салават күпере кояшның көнчыгышта булуын, ә яңгырның көнбатышта явуын күрсәтә. Өйләдән соңгы салават күпере вакытында кояшның көнбатышта булуын, ә яңгырның көнчыгышта явуын сиземләп була.

Урысчадан
***ЛИЛИЯ СӘХАПОВА** тәрҗемәсе.*

Рәссам НАТАЛЬЯ ЕВСТАФЬЕВА

ЧТО ТАКОЕ РАДУГА?

Радуга — одно из самых красивых явлений природы, и люди уже давно задумывались над ее природой. Даже Аристотель, древнегреческий философ, пытался объяснить причину радуги.

Солнечный луч или обычный луч белого света в действительности является сочетанием всех цветов. Ты, наверное, замечал, что происходит, когда луч света попадает на скошенный краешек зеркала или на поверхность мыльного пузыря. Белый луч распадается на различные цвета. Мы увидим красный, оранжевый, желтый, зеленый, синий и фиолетовый цвета.

Предмет, который может разложить луч света на его составляющие, называется «призмой». Образуемые цвета создают полоску из цветных сочетающихся линий, которая называется «спектр».

Радуга и есть большой изогнутый спектр, или полоса цветных линий, образовавшихся в результате разложения луча света, проходящего через капельки дождя. В данном случае капли дождя выполняют роль призмы.

Радуга появляется только во время ливня, когда идет дождь и одновременно светит солнце. Находиться необходимо строго между солнцем (оно должно быть сзади) и дождем (он должен быть перед тобой). Иначе радуги не увидеть! Солнце, ваши глаза и центр радуги должны находиться на одной линии!

Если солнце высоко в небе, провести такую прямую линию невозможно. Вот почему радугу можно наблюдать только ранним утром или ближе к вечеру. Утренняя радуга означает, что солнце находится на востоке, а дождь идет на западе. При послеобеденной радуге солнце расположено на западе, а дождь — на востоке.

Художник НАТАЛЬЯ ЕВСТАФЬЕВА

Аркадий Мельников

ТУЗАН СУЫРТКЫЧ

«Пылесос» дип атала ул
Безнең тузан суырткыч,
Әти сатып алган иде,
Әй усал да соң, ерткыч!
Мышлый-пышлый көнозын,
Борын — филдән дә озын —
Суыра, йота бара,
Кара син, йөзе кара —
Тамагы туйган, откан —
Тишек оекны йоткан.
Тыңламый сүз-вәгазьне,
Йоткан бөтен кәгазьне,
Барын суырган дисәм —
Уенчык филем исән...
Син тузан суырткыч, болай
Бүлмәмә керер булсаң,
Иң шәбе булыр, мин үзем
Аның идәнен юсам...

*РӘФИС ӘХМӘТ
тәрҗемәсе*

Рәссам АЛЛА АЙСИНА

Аркадий Мельников

ПЫЛЕСОС

Мы купили пылесос,
У него огромный нос.
Носом он работает,
Убирает пыль.
И рычит он громко,
Как автомобиль.
Может он так сердится,
И рычит, и лает.
На того, кто в комнате
Плохо убирает.

Художник АЛЛА АЙСИНА

ЫШАНЫЧЛЫ ЧАРА

Эт баласының теше сызлады, бөтен бите шешенде.

Эт баласы ишегалдында йөри, елый, ә дуслары исә аңа төрле киңәшләр бирәләр.

— Мин ышанычлы чара беләм,— дип чөрелдәде кыпшы чыпчык.— Авыртуы узганчы эт баласын кытыкларга кирәк.

— Ахмаклык!— дип аны бүлдерде тычкан баласы Мыша.— Уналты чистарткыч алырга һәм эт баласына массаж ясарга кирәк. Авыртуы шундук бетәр!

— Бу ышанычлы чара, ләкин ул бары тычканнарга гына булыша,— дип җитди әйтеп куйды чучка баласы.— Ә эт балаларына кирәк...

— Тешләрне чистартырга кирәк!— диде керпе баласы.— Теш щеткасы белән! Иң ышаныч чара шул!

Урысчадан ***ЛИЛИЯ СӘХАПОВА*** *тәрҗемәсе.*

ВЕРНОЕ СРЕДСТВО

Заболел у щенка зуб, всю щеку раздуло.

Ходит щенок по двору, плачет, а друзья разные советы дают.

— Я знаю верное средство,— щебечет щегол.— Надо щенка щекотать, пока боль не пройдет.

— Глупости!— прервал его мышонок Мыша.— Надо взять шестнадцать щеток и сделать щенку массаж. Боль как рукой снимет!

— Это средство верное, но помогает только мышам,— серьезно сказал поросенок.— А щенкам надо...

— Зубы чистить надо!— сказал ежонок.— Зубной щеткой! Вот самое верное средство!

Рәссам НАТАЛЬЯ АНИКИНА

Художник НАТАЛЬЯ АНИКИНА

ИЗУЧАЕМ ЯЗЫКИ
ТЕЛЛӘРНЕ ӨЙРӘНӘБЕЗ

ЮНЫЕ ДРУЗЬЯ!

УРОК • 20 • ДӘРЕС

«ИЗУЧАЕМ ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК»

ДВАДЦАТЫЙ УРОК
(Егерменче дәрес)

1. Гөмбәләр турында сөйләшәбез.

— Сез гөмбә җыярга барасызмы?
— Нинди гөмбәләр беләсез?
— Гөмбәләр кайда үсә?
— Ашарга яраклы гөмбәләрне ничек аерасыз?

АШАРГА ЯРАКЛЫ ГӨМБӘЛӘР:

Ак гөмбә.

Гөреҗдә.

Баллы гөмбә.

Майлы гөмбә.

Каен гөмбәсе.


Усак гөмбәсе.

Әтәч гөмбәсе.

Нарат гөмбәсе.


Җирән гөмбә.

Ал гөмбә.

НИНДИ АГУЛЫ ГӨМБӘЛӘР БУЛА?

Кәҗә гөмбәсе.


Йөнтәс гөмбә.

ЧЕБЕН ГӨМБӘСЕ.

АК ТОМСЫК АГУЛЫ ГӨМБӘ.

ЯЛГАН БАЛЛЫ ГӨМБӘ.

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ (Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМОВ)

СҮЗЛЕК

ашарга яраклы — *съедобный*
ак гөмбә — *белый гриб*
гөреждә — *груздь*
баллы гөмбә — *опенок*
майлы гөмбә — *масленок*
каен гөмбәсе — *подберезовик*
усак гөмбәсе — *подосиновик*
нарат гөмбәсе — *боровик*
ялган баллы гөмбә — *ложный опенок*
җирән гөмбә — *рыжик*
ал гөмбә — *сыроежка*
йонтәс гөмбә — *волнушка*
мүк гөмбәсе — *моховик*
кара гөмбә — *чернушка*
агулы гөмбә — *ядовитый гриб*
чебен гөмбәсе — *мухомор*
әтәч гөмбәсе — *лисичка*
кәҗә гөмбәсе — *сморчок*
ак томсык агулы гөмбә — *белая поганка*

2. Хәтердә тотыгыз:

Татар телендә сүзләрнең кушма төрләре киң кулланыла:

кушма сүзләр (сложные слова) — ярканат *(летучая мышь)*, бозваткыч *(ледокол)*, көньяк *(юг)*.

парлы сүзләр (парные слова) — ата-ана *(родители)*, савыт-саба *(посуда)*, мал-туар *(скот)*.

тезмә сүзләр (составные слова) — бал корты *(пчела)*, кура җиләге *(малина)*, тимер юл *(железная дорога)*.

3. Көзге табигать турында сөйләшү.
Соңыннан җөмләләрне урысча әйтегез.

Көз көне яшелчәләр, җиләк-җимешләр өлгереп җитә. Кырда игеннәр җыелып бетә. Көннәр салкынайта. Кошлар җылы якка китәләр. Яңгырлар еш ява.

4. Көн исемнәрен хәтердә калдырыгыз:

дүшәмбе — понедельник
сишәмбе — вторник
чәршәмбе — среда
пәнҗешәмбе — четверг
җомга — пятница
шимбә — суббота
якшәмбе — воскресенье



Вакытны белдергән сүзләргә игътибар итегез:

ел — год
ай — месяц
атна — неделя
тәүлек — сутки
быел — в этом году
былтыр — в прошлом году

үткән ел — прошлый год
киләсе ел — будущий год
сәгать — час
төн — ночь
көн — день
ярты ел — полгода

5. Шигырьне күңелдән ятлагыз:

КӨЗ

Үтте-китте матур җәйләр.
Көзләр килеп җиттеләр.
Ак каенның яфраклары
Саргаешып беттеләр.

К. НӘҖМИ.

6. Мәктәп, укучы, дәфтәр, китап, сыйныф, укыйм, язам сүзләре кергән җөмләләр төзегез.

7. Табышмаклар нәрсәне аңлата?



Үзе сөйли,
үзе көйли,
Ә үзенең
теле юк.

(*Телефон.*)

Теле юк,
Үзе аңлата.

(*Китап.*)

Мәкальләрне урысчага тәрҗемә итегез:

Авыздан чыккан сүз — атылган ук. Туры сүз — телнең бизәге.
Уйнап сөйләмә, уйлап сөйлә.

*Дәресне филология фәннәре докторы, профессор **ВАХИТ ХАКОВ** алып бара.*

*Урок ведет доктор филологических наук, профессор **ВАХИТ ХАКОВ.***

Әхлакый тәрбия

Каюм Насыри

Китаб-әт-тәрбия



(УНБЕРЕНЧЕ ТӘРБИЯ)

ИСКӘНДӘР РУМИДАН СОРАДЫЛАР: «МӘШРИКЪ ВӘ МӘГЪРИБ ИЛЛӘРЕН НИЧЕК ИТЕП АЛДЫҢ. ЭЛКЕГЕ ПАДИШАҺЛАР НИКАДӘР ГАСКӘР ВӘ АКЧА, ВӘ ХӘЗИНӘ ТҮГЕП ТӘ АЛАЛМАГАННАР ИДЕ»,— ДИДЕЛӘР. ИСКӘНДӘР ӘЙТТЕ: «ҺӘР МӘМЛӘКӘТНЕ АЛДЫМ, ХАЛКЫН РӘНҖЕТМӘДЕМ. ВӘ ЭЛГӘРЕ ПАДИШАҺЛАРНЫ ИЗГЕЛЕКТӘН ГАЙРЕ НӘРСӘ БЕЛӘН ЗЕКЕР КЫЙЛМАДЫМ»,— ДИДЕ. ӘЙ УГЫЛ, ИНДЕ КҮРДЕҢ, НИНДӘЕН ТӘРБИЯЛЕ КЕШЕЛӘР БАР, ИМЕШ. ХИЛЕМ ВӘ ЙОМШАКЛЫК БЕЛӘН БӨТЕН МӘМЛӘКӘТНЕ ЯУЛАП АЛАЛАР; ХИЛЕМ ВӘ ЙОМШАК СҮЗЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ: ГӘРЧӘ ДОШМАНЫҢ БУЛСА ДА, ИЗГЕЛЕКТӘН ГАЙРЕ ЗЕКЕР КЫЙЛМАГАЙСӘН.

Рәссам ЗАҺИР ХӘКИМОВ

Нравственное воспитание

Каюм Насыйри

Книга о воспитании

(НАСТАВЛЕНИЕ ОДИННАДЦАТОЕ)

АЛЕКСАНДРА МАКЕДОНСКОГО СПРОСИЛИ: «КАК УДАЛОСЬ ТЕБЕ ДОБИТЬСЯ ПОКОРНОСТИ НА ВОСТОКЕ И ЗАПАДЕ? ПРЕЖНИЕ ПРАВИТЕЛИ НЕ ЖАЛЕЛИ НИ ВОЙСК, НИ СОКРОВИЩ, А НЕ СМОГЛИ ЗАВОЕВАТЬ СТОЛЬКО СТРАН». АЛЕКСАНДР ОТВЕТИЛ: «Я БРАЛ СТРАНЫ, НО НЕ ОБИЖАЛ НАРОД. А ПРЕЖНИХ ПРАВИТЕЛЕЙ ПОМИНАЛ ТОЛЬКО ДОБРОМ».

О СЫН МОЙ, ВИДИШЬ, СКОЛЬ МОГУЧ ВОСПИТАННЫЙ ЧЕЛОВЕК? ДОБРОТА И КРОТОСТЬ БЕРУТ ГОРОДА; НАДО БЫТЬ ДОБРЫМ И СНИСХОДИТЕЛЬНЫМ КО ВСЕМ, ОСТЕРЕГАЙСЯ ГОВОРИТЬ ДУРНО ДАЖЕ О СВОИХ ВРАГАХ.

Художник ЗАГИР ХАКИМОВ

Мирас
Наследие

Габдулла Тукай

Су анасы

(Шигъри әкият)

II

ЯХШЫ, ХУШ. БАТТЫ КОЯШ. ЙОКЛАРГА ЯТТЫМ КИЧ БЕЛӘН;
ӨЙ ЭЧЕ ТУЛГАН ИДЕ КИЧКЕ ҺАВА, ХУШ ИС БЕЛӘН.

ЮРГАН АСТЫНДА ЙОКЫГА КИТМИ ЯТАМ МИН ҺАМАН;
ШЫК ТА ШЫК! — КЕМДЕР ТӘРӘЗӘГӘ ЧИЕРТӘ БЕР ЗАМАН.

МИН ЯТАМ РӘХӘТ КЕНӘ, ТОРМЫЙМ ДА КУЗГАЛМЫЙМ ӘЛЕ.
БУ ТАВЫШКА СИСКӘНЕП, ТОРГАН ЙОКЫСЫННАН ӘНИ:

— НИ КИРӘК? КЕМ 6У? КАРА ТӨНДӘ ВАКЫТСЫЗ КЕМ ЙӨРИ?
НӘРСӘ БАР СОҢ ТӨНЛӘ БЕРЛӘН, И ПЫЧАГЫМ КЕРГЕРЕ!

— СУ АНАСЫ МИН, КИТЕР, КАЙДА МИНЕМ АЛТЫН ТАРАК?
БИР! БАЯ КӨНДЕЗ АЛЫП КАЧТЫ СИНЕҢ УГЪЛЫҢ, КАРАК!

ТӨШКӘН АЙНЫҢ ШӘҮЛӘСЕ, МИН ЮРГАН АСТЫННАН КАРЫЙМ;
КАЛТЫРЫЙМ, КУРКАМ: «ХОДАЙ! — ДИМ, — ИНДЕ МИН КАЙДА БАРЫЙМ?»

ҺИЧ ӨЗЕКСЕЗ ШЫК ТА ШЫК! БЕЗНЕҢ ТӘРӘЗӘНЕ КАГА;
УЛ КОТОЧКЫЧ САЧЛӘРЕННӘН ЧИШМӘ ТӨСЛЕ СУ АГА.

ӘНКӘЕМ АЛТЫН ТАРАКНЫ, ТИЗ ГЕНӘ ЭЗЛӘП ТАБЫП,
АТТЫ ДА ТЫШКА, ТИЗҮК КУЙДЫ ТӘРӘЗӘНЕ ЯБЫП.

СУ АНАСЫННАН КОТЫЛГАЧТЫН, ТЫНЫЧЛАНГАЧ, ӘНИ
И ОРЫШТЫ, И ОРЫШТЫ, И ОРЫШТЫ СОҢ МИНЕ!

МИН ДӘ ШУННАН БИРЛЕ АНДЫЙ ЭШКӘ КЫЙМЫЙ БАШЛАДЫМ,
«ЙӘ ИЯСЕ ЮК!» — ДИП, ӘЙБЕРЛӘРГӘ ТИМИ БАШЛАДЫМ.

(Әкият тәмам.)

Рәссам ЗӨФӘР ХӘКИМОВ

Мирас
Наследие

Габдулла Тукай

Водяная

(Поэтическая сказка)

II

ВОТ УЖЕ И СОЛНЦЕ СЕЛО. ЛЕГ Я СПАТЬ, И СВЕТ ПОТУХ.
ЗА ОКНОМ — ДУШИСТЫЙ ВОЗДУХ, В ДОМЕ СВЕЖИЙ ХЛЕБНЫЙ ДУХ.

СОН НЕЙДЕТ КО МНЕ УПРЯМО, ХОТЬ УСНУТЬ ПОРА ДАВНО.
СТУК-СТУК-СТУК! — ВНЕЗАПНО СЛЫШУ. ЭТО КТО СТУЧИТ В ОКНО?

НО ПРИГРЕЛСЯ Я В ПОСТЕЛИ, НЕОХОТА МНЕ ВСТАВАТЬ.
ОТ НОЧНОГО СТУКА ВЗДРОГНУВ, ПОДНЯЛАСЬ С ПОСТЕЛИ МАТЬ.

— КТО ТАМ В ПОЛНОЧЬ КОЛОБРОДИТ! ТЬМА — НЕ ВИДНО НИЧЕГО!
НУ, ЧЕГО ЕЩЕ ТУТ НАДО? ГРАБЯТ, ЧТО ЛИ, ТАМ КОГО?

— ВОДЯНАЯ Я, ОТКРОЙТЕ! ГДЕ МОЙ ГРЕБЕНЬ ЗОЛОТОЙ?
ЗНАЙ, НА ОЗЕРЕ СЕГОДНЯ ВОРОМ СТАЛ СЫНОЧЕК ТВОЙ!

ТЕНЬ ЕЕ В ОКОШКЕ ЛУННОМ: НАКРЫВАЮСЬ С ГОЛОВОЙ.
НУ, КУДА ТЕПЕРЬ ДЕВАТЬСЯ?! — ВЕСЬ ДРОЖУ Я, БОЖЕ МОЙ!

ВОДЯНАЯ ВСЕ СТУЧИТСЯ: ТОНКОЕ СТЕКЛО ДРОЖИТ,
С ГОЛОВЫ ЕЕ РУЧЬЯМИ ВЛАГА ЧИСТАЯ БЕЖИТ...

МАТУШКА ЗЛОСЧАСТНЫЙ ГРЕБЕНЬ ОТЫСКАЛА, — КИНУВ ЕЙ,
ОТ ГРЕХА ОНА ОКОШКО ЗАТВОРИЛА ПОСКОРЕЙ.

ВИДИТ: БОЛЬШЕ НЕТ НАПАСТИ, И РУГАТЬ МЕНЯ ДАВАЙ!
ВОТ РУГАЛА, ВОТ РУГАЛА, ВОТ ДАЛА МНЕ НАГОНЯЙ!

С ТОЙ-ТО ВЗБУЧКИ МАТЕРИНСКОЙ НАУЧИЛСЯ Я ДОБРУ.
ЕСТЬ ХОЗЯИН ИЛИ НЕТУ — ВВЕК ЧУЖОГО НЕ БЕРУ.

(Конец сказки.)

Художник ЗУФАР ХАКИМОВ

Тәймәкәй

Ганс Христиан Андерсен

Төнлә Төймәкәй йоклый алмады. Ул ятактан торды, кипкән үлән сабагыннан зур келәм үрде, җир асты юлыннан чыгып, келәм белән үлгән кошны каплады.

Аннан соң Төймәкәй тычкан өненнән йомшак һәм җиңел мүк алып килде һәм үлгән кошка яту өчен уңайлы булсын дип, аңардан ястык ясады.

— Хуш, кадерле карлыгачым! — диде Төймәкәй.— Хуш! Җәен агачлар яшел яфрак яргач, кояш нурлары җылытканда миңа матур итеп җыр җырлавың өчен рәхмәт сиңа!

Һәм ул үзенең башын кошның күкрәгенә куйды һәм кинәт куркып китте: ул карлыгач күкрәгендә нәрсәнеңдер тибүен ишетте. Кошның йөрәге шулай тибә икән, ул әле үлеп җитмәгән, бары салкынга күшеккән иде. Ә хәзер исә җылынды һәм терелде.

Төймәкәй куркуыннан дерелди башлады, чөнки кош аның кебек нәни белән чагыштырганда галәмәт зур иде. Ләкин шулай да Төймәкәй исенә килде, карлыгачны келәм белән яхшырак төрде дә, аннан соң йөгереп, үзе бөтнек яфрагын алып килде һәм аның белән кошның башын каплады.

Икенче төнне дә Төймәкәй кабат сак кына кош янына килде. Карлыгач инде төмам терһәкләнеп беткән, ләкин әле бик хәлсез иде һәм кызга карау өчен күзләрен дә көч-хәл белән генә ачты.

Урысчадан
ЛИЛИЯ СӘХАПОВА
тәрҗемәсе.

(Дәвамы бар.)

Дюймовочка

Ганс Христиан Андерсен

Ночью Дюймовочке не спалось. Она встала с постельки, сплела из сухих былинок (травинок) большой ковер, пошла в подземный ход и прикрыла ковром мёртвую птичку.

Потом Дюймовочка принесла из мышиной норки пушистый, мягкий мох и устроила из него постельку, чтобы мертвой птичке было удобнее лежать.

— Прощай, милая ласточка! — сказала Дюймовочка. — Прощай! Спасибо тебе за то, что ты так чудесно пела мне летом, когда деревья были еще зеленые, а солнышко так славно грело!

И она склонила головку на грудь птички и вдруг испугалась: она услышала, как в груди ласточки что-то стучит. Это забилось сердце птицы — она была не совсем мертвая, а только окоченела от холода. А теперь она согрелась и ожила.

Дюймовочка дрожала от страха — ведь птица была просто великаном по сравнению с такой крошкой. Но все-таки Дюймовочка собралась духом, поплотнее закутала ласточку ковриком, а потом сбегала, принесла листок мяты, которым сама укрывалась, и покрыла им голову птицы.

На следующую ночь Дюймовочка опять потихоньку пробралась к птице. Ласточка уже совсем ожила, только была еще очень слаба и еле-еле открыла глаза, чтобы посмотреть на девочку.

(Продолжение следует.)

Художник АЛЛА АЙСИНА

Гөлшат Зәйнашева

Мәктәп бакчасы



БЕЗНЕҢ МӘКТӘПНЕҢ БАКЧАСЫ
ТАУ БИТЕНДӘ, БОЛЫНДА.
ЧӘЧӘКЛӘРГӘ КҮМЕЛӘ УЛ
ҖЫЛЫ КОЯШ НУРЫНДА.

ЭХ БАКЧАБЫЗ, БАКЧАБЫЗ ДА,
ЯМЬЛЕ БЕЗНЕҢ БАКЧАБЫЗ.
БАКЧАБЫЗДА ЭШЛӘП АРГАЧ
ҖЫРЛАП КҮҢЕЛ АЧАБЫЗ!

Рәссам ЮЛИЯ ЩЕТИНКИНА

Гульшат Зайнашева

ШКОЛЬНЫЙ САД

ШКОЛЬНЫЙ САД НАШ НА ПРИГОРКЕ
ТОЛЬКО-ТОЛЬКО СНЕГ РАСТАЕТ,
ПОД ЛУЧАМИ АЛОЙ ЗОРЬКИ
ВЕСЬ В ЦВЕТОЧКАХ УТОПАЕТ.

АХ НАШ САДИК, ЧУДО-САДИК,
ПОРАБОТАВ ТАМ НА СЛАВУ,
МЫ ПОЕМ, ИГРАЕМ, ПЛЯШЕМ,
ПРИНОСЯ ЦВЕТАМ УСЛАДУ!

Перевод
РАФИСА АХМЕТА.



Художник ЮЛИЯ ЩЕТИНКИНА

Цена договорная